РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 01 июль** **Чистай шәһәре** **№ 104**

«Имин шәһәр» АПК системаларын җәелдерү
буенча ведомствоара эшче төркем составын
һәм нигезләмәсен раслау турында

«Имин шәһәр» техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертү һәм үстерү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турында» 2015 елның 20 мартындагы 455-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы, шулай ук 2004 елның 23 декабрендәге 14-7-548 номерлы «Имин шәһәр» техник чараларының аппарат комплексын төзү һәм үстерү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планы нигезендә, «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чистай шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Имин шәһәр» АПК системаларын җәелдерү буенча ведомствоара эшче төркем составын һәм нигезләмәсен кушымталар нигезендә расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Ф.М. Садыйков

Чистай шәһәре Башкарма
комитетының 2022 елның 1
июльдәге 104 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертү һәм үстерү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» техник чараларының аппарат-программа комплексы системаларын гамәлгә кертү һәм үстерүгә бәйле мәсьәләләр буенча Ведомствоара эшче төркем (алга таба - Ведомствоара эшче төркем) Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» техник чараларының аппарат - программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен эшләү өчен оештырылган координацион орган булып тора.

2. Ведомствоара эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Ведомствоара эшче төркемнең төп бурычы - Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» техник чараларның аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен эшләү.

4. Ведомствоара эшче төркем әлеге бурычларны хәл иткәндә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, галимнәр һәм экспертлар белән хезмәттәшлек итә.

5. Ведомствоара эшче төркем хокуклы:

- Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, территориаль органнардан, федераль башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан ведомствоара эшче төркем компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча кирәкле материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

- Ведомствоара эшче төркем компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча координацион киңәшмәләр һәм эшлекле очрашулар оештырырга һәм билгеләнгән тәртиптә үткәрергә;

- Ведомствоара эшче төркем эшчәнлегенә фәнни-тикшеренү, белем бирү оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләр белгечләрен билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә.

6. Ведомствоара эшче төркем составына рәис, рәиснең ике урынбасары, җаваплы секретарь, шулай ук министрлыклар, ведомстволар һәм предприятиеләр вәкилләреннән торган ведомствоара эшче төркемнең башка әгъзалары керә.

7. Ведомствоара эшче төркем рәисе:

- Ведомствоара эшче төркем эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

- Ведомствоара эшче төркем утырышларын үткәрү урынын һәм вакытын, шулай ук аларның көн тәртибен билгели;

- Ведомствоара эшче төркем эшчәнлеген оештыра һәм аның карарларын үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итә;

- Ведомствоара эшче төркем тарафыннан аның компетенциясенә керүче аерым мәсьәләләрне карау тәртибен билгели.

8. Ведомствоара эшче төркем рәисе вакытлыча булмаган чорда Ведомствоара эшче төркем эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне Ведомствоара эшче төркем рәисе урынбасары башкара.

9. Ведомствоара эшче төркем утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

Ведомствоара эшче төркем утырышын Ведомствоара эшче төркем рәисе алып бара.

Ведомствоара эшче төркем утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

Ведомствоара эшче төркем әгъзалары утырышларда алыштыру хокукы булмаган килеш катнаша. Ведомствоара эшче төркем әгъзасы булмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча язма рәвештә үз фикерен тапшырырга хокуклы.

10. Ведомствоара эшче төркем карарлары Ведомствоара эшче төркем әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырышта рәислек итүче һәм Ведомствоара эшче төркемнең җаваплы секретаре кул куя торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

11. Ведомствоара эшче төркем эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы башкара.

Чистай шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 01 июнендәге 104 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«Имин шәһәр» АПК системаларын җәелдерү буенча ведомствоара эшче төркем**
**СОСТАВЫ**

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Рәхимов Илдар Фаил улы | Чистай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе – **эшче төркем рәисе** |
| 2. | Садыйков Фарход Мурод улы | Чистай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - **эшче төркем рәисе урынбасары** |
| 3. | Кипров Артем Юрьевич | «Татарстан Республикасы буенча 67 ПЧ ФПС» ФГКУ башлыгы - **эшче төркем рәисе урынбасары** (килешү буенча) |
| 4. | Сафиуллина Альбина Илдар кызы | Чистай шәһәре Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге баш белгече – **эшче төркем секретаре** |
| 5. | Емельянов Павел Борисович | Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| 6. | Карманова Наталья Анфиногентовна | Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| 7. | Акимов Олег Александрович | Чистай буенча РФ ФКХИ бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 8. | Денисов Олег Геннадьевич | Россия Эчке эшләр министрлыгының Чистай муниципаль районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 9. | Сироткин Валерий Александрович | Чистай муниципаль районы буенча ТР ГТХМ идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 10. | Сергеев Василий Викторович | ООП төркеме инспекторы полиция капитаны (килешү буенча) |
| 11. | Мостафин Рәис Роберт улы | «Чистай РҮХ» ДАССОның баш табибы (килешү буенча) |
| 12. | Әхмәтҗанов Рәфис Габделхалик улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының территориаль идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 13. | Лифанов Валерий Владимирович | Әлмәт ЗУЭСы башлыгы урынбасары - Чистай МРУЭСы башлыгы (килешү буенча) |
| 14. | Рәхмәтуллина Эльвира Мансур кызы | «Чистопольский автодор» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) |
| 15. | Аминов Ленар Рәшит улы | «СК» Чистай электр челтәрләре ААҖ филиалы Чистай РЭСы башлыгы (килешү буенча) |
| 16. | Шәфыйков Мисхәт Мәгъсүмҗан улы | «Газпром Трансгаз Казань» ҖЧҖ «Чистопольгаз» эксплуатация-җитештерү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| 17. | Харисов Марат Әсхәт улы | «Чистопольские ПТС» ААҖ генераль директоры (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 18. | Әхмәтҗанов Тәлгать Әнәс улы | «Чистополь-водоканал» АҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| 19. | Гыйззәтуллин Әсхәт Сәмигулла улы | «Жилремсервис» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) |